| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 15 октябре** **№ 24**

Куакбаш авыл җирлеге Советының 2015 елның 17 декабрендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 31 декабрендәге 503-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Куакбаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Куакбаш авыл җирлеге Советының 2015 елның 17 декабрендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлегендәге 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә калдыкларны кабул итүне оештыру тәртибе турында нигезләмә (алга таба - нигезләмә) Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру (алга таба-нигезләмә) барышында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.»;

1.4 пунктта «җыю һәм транспортлау буенча» сүзләрен «кабул итүне оештыру

буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1.1бүлектә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә калдыкларны кабул итү, аларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру максатларында калдыкларны кабул итүне оештыру.»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсуслаштырылган оешмалар - каты көнкүреш калдыкларын җыю, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлек алып баручы шәхси эшмәкәр яки юридик зат.»;

2.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. Калдыкларны транспортлауны оештыру-калдыкларны кабул итү урыннарыннан аларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру урыннарына күчерү буенча махсуслаштырылган оешмалар эшчәнлеге.»;

3. Әлеге карарны Куакбаш авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Куакбаш авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова